РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

22.12.2015

№ 182-п

Учреждение, оешма һәм
предприятиеләр арасында
“Талант-шоу - 2016 ” дип исемләнгән
конкурс–кичә үткәрү турында

Районыбыз хезмәт ияләренең, аеруча яшьләрнең, ялын файдалы итеп оештыру һәм хезмәт кешесенең рухи ихтыяҗын баету, халык талантларын үстерү, шулай ук төрле яшьтәге кешеләрне мәдәният тормышына якынайту, яшь буында татар халык көйләренә, җырларына мәхәббәт тәрбияләү, аларның активлыгын үстерү максатыннан,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2016 елның гыйнварыннан маена кадәр район учреждениеләре, оешма һәм предприятиеләре арасында “Талант-шоу - 2016” дип исемләнгән конкурс-кичә үткәрергә.

2. “Талант-шоу - 2016” дип исемләнгән конкурс-кичәне (алга таба – конкурс-кичә) оештыру нигезләмәсен, оештыру комитеты составын, үткәрү графигын, жюри составын расларга. (1,2,3,4 кушымталар).

3. Графикта күрсәтелгән учреждение, оешма һәм предприятие җитәкчеләренә үз коллективларының конкурс-кичәдә катнашуын оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Учреждение, оешма һәм предприятие җитәкчеләренә, мәдәният хезмәткәрләренә, урыннардагы белгечләргә конкурс-кичәдә катнашучы коллективларга иҗади ярдәм күрсәтүне оештырырга тәкъдим итәргә.

7. Конкурс-кичәне үткәрү урыны итеп Саба район һәм Шәмәрдән авыл мәдәният йортларын билгеләргә. Бу мәдәният йортларының җитәкчеләренә (А.Н.Гүзәлов, Р.Хаҗиева) конкурс-кичәне үткәрү өчен бөтен шартларны булдыруны тәкъдим итәргә.

8. «Саба таңнары» газетасы редакциясенә (Исмәгыйлов Р.Г.) һәм “Саба дулкыннары” телерадиокомпаниясенә (Мөбәрәкова Ә.Г.) конкурс-кичәнең барышын даими яктыртып баруны тәкъдим итәргә.

9. Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ш.Ә.Сөнгатовка конкурс-кичәдә катнашкан коллективларны бүләкләү өчен финанс чыганаклары табуны тәкъдим итәргә.

10. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.М.Гасимовка йөкләргә.

Глава Сабинского
муниципального района Р.Н.Минниханов

1 кушымта
Саба муниципаль район башлыгының
22.12.2015 ел №182-п карары
белән расланды

Учреждение, оешма һәм предприятиеләр арасында
“Талант-шоу - 2016”
дип исемләнгән конкурс-кичәне оештыру

Нигезләмәсе

1. Конкурс-кичәне оештыруның максаты:
- яшьләрнең һәм хезмәт ияләренең ялын файдалы итеп оештыру,
- халык талантларын үстерү,
- халкыбызның күңел байлыгы булган җырларны саклап калу һәм яшь буынга җиткерү,
- төрле яшьтәге кешеләрне мәдәният тормышына якынайту, хезмәт кешесенең рухи ихтыяҗын баету.

2. Конкурс-кичәне үткәрү тәртибе һәм шартлары:
“ Талант-шоу - 2016” конкурс-кичәсендә райондагы учреждение, оешма һәм предприятиеләрдән җырларга, биергә, төрле уен коралларында уйнарга, халыкны көлдерергә, оригиналь жанр белән чыгыш ясарга сәләте булган һәр кеше катнаша ала.

3. Конкурс-кичәнең номинацияләре:
Вокал жанр: (соло, дуэт, ансамбль)
Бәяләү критерийләре: (музыкальлек, интонация чисталыгы, тавыш сыйфаты, тембр үзенчәлеге, тавыш көчлелеге, башкару осталыгы, сәхнә костюмы.

Бию жанры: (эстрада, заманча, классика, халык биюләре һ.б.)
Бәяләү критерийләре: (хәрәкәтләр ясау техникасы, номерның композицион төзелеше, сценичность (пластика, костюм, башкару осталыгы), артистизм, сәхнә образын ачу.

Инструменталь жанр: (соло, ансамбль)
Бәяләү критерийләре: музыкаль композицияне җиткерү осталыгы, уен коралында уйнау осталыгы, әсәрнең катлаулылыгы.

Оригиналь жанр: (эстрада миниатюрасы, пародия, цирк номеры, фокус, юмор (КВН-формат), эксцентрик номер (үзенчәлеге белән башкалардан аерылып торучы)
Бәяләү критерийләре: башкару үзенчәлеге, оригинальлек.

Фольклор жанры: (бәет, мөнәҗәт, йола, фольклор музыкасы)

Бәяләү критерийләре: уйнау осталыгы, артистизм, яңалык (моңарчы күрелмәгән йола, ишетелмәгән бәет-мөнәҗәтләрне башкару).

Конферансье:

Бәяләү критерийләре: кичәне алып бару осталыгы, дикция, тавыш тембры, артистизм.

4. “Талант-шоу - 2016” конкурс–кичәсе җиңүчеләре гала-концертта чыгыш ясаячак һәм дипломнар, акчалата премияләр белән бүләкләнәчәк.

5. Комиссия әгъзалары карары нигезендә иң яхшы номер белән чыгыш ясаучы “Гран-при” иясе итеп билгеләнергә мөмкин.

6. Һәр учреждение, оешма һәм  предприятие “Талант-шоу – 2016” дипломы белән бүләкләнәчәк.

Искәрмә: Конкурс-кичәдә һәр катнашучы тере тавышка чыгыш ясарга тиеш. Бары тик “минусовка” фонограмма гына кулланыла ала.

2 кушымта
Саба муниципаль район башлыгының
22.12. 2015 ел №182-п карары
белән расланды

Учреждение, оешма һәм предприятиеләр арасында
“Талант-шоу - 2016” конкурс-кичәсен
үткәрү буенча оештыру комитеты составы

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гасимов Р.М. | - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, оештыру комиссиясе рәисе |
| 2 | Шәрәфиев Т.Г. | - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең Беренче урынбасары, оештыру комиссиясе рәисе урынбасары |
| 3 | Заһидуллин Р.Ф. | - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәният бүлеге начальнигы |
| 4 | Исмәгыйлов Р.Г. | - “Саба таңнары” газетасы мөхәррире (килешү буенча) |
| 5 | Мөбәрәкова Ә.Г | - “Саба дулкыннары” телерадиокомпаниясе директоры (килешү буенча) |
| 6 | Сөнгатов Ш.Ә. | - Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе |

3 кушымта
Саба муниципаль район башлыгының
22.12. 2015 ел №182-р карары
белән расланды

Учреждение, оешма һәм предприятиеләр
арасында “Талант-шоу - 2016” дип исемләнгән
конкурс–кичәне үткәрү графигы

| № | Учреждение, оешма һәм предприятие исеме | Узачак көне |
|---|---|---|
| 1 | Сәләтле балалар өчен аерым предметларны тирәнтен өйрәнелә торган урта гомуми белем мәктәп-интернаты | 22.01.2016 |
| 2 | Саба гимназиясе | 05.02.2016 |
| 3 | Саба аграр көллияте | 12.02.2016 |
| 4 | “Сабагаз” эксплуатация җитештерү идарәсе | 19.02.2016 |
| 5 | “Ак Барс” ачык акционерлык җәмгыятенең Казан филиалы Саба өстәмә офисы<br>“Россия саклык банкы” ачык акционерлык җәмгыятенең 4642 нче номерлы Саба бүлекчәсе<br>Татфондбанк “АИКБ” ачык акционерлык җәмгыятенең Б.Сабасы өстәмә офисы<br>Россельхозбанк ачык акционелык җәмгыятенең Татарстан региональ филиалы Б.Сабасы ш.т.б. өстәмә офисы | 26.02.2016 |
| 6 | “Торак-коммуналь хуҗалыгының Саба күптармаклы җитештерү предприятиесе” ачык акционерлык җәмгыяте<br>Район халыкны социаль яклау бүлеге<br>“Балкыш” социаль хезмәт күрсәтү үзәге һәм Шәмәрдән реабилитация үзәге, эш һәм мәшгульлек үзәге | 04.03.2016 |
| 7 | Район үзәк шифаханәсе<br>31 нче номерлы район үзәк аптекасы<br>“Казан аптекалары” | 11.03.2016 |
| 8 | Россия эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге<br>“Саба дулкыннары” ТРК<br>“Саба таңнары” редакциясе | 18.03.2016 |
| 9 | Район почта элемтәсе идарәсе<br>Район электр элемтәсе узелы<br>Район электр челтәре, Энергосбыт, Энергонадзор | 24.03.2016 |
| 10 | “Татавтодор” ачык акционерлык җәмгыятенең Саба филиалы | 01.04.2016 |
| 11 | Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10 нчы районара инспекциясе | 08.04.2016 |
| 12 | “Олимп” балалар-яшьүсмерләр спорт мәктәбе<br>“Спорткомплекс” муниципаль учерežдениясе<br>«Саба йөзү бассейны физкультура-сәламәтләндерү комплексы” муниципаль учреждениесе | 15.04.2016 |

| | | |
|---|---|---|
| 13 | Сак бүлеге (отдел охраны), Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе<br>ТР хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге<br>Татарстан Республикасындагы Федераль миграция идарәсенең Саба районындагы бүлекчәсе<br>Прокуратура, район суды, суд приставлары хезмәте, адвокатура | 22.04.2016 |
| 14 | “Саба МТС” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Сабагрохим” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Илфани”, “Тулпар”, “Сабинскагпроромснаб” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләре | 29.04.2016 |
| 15 | Федераль казначылык идарәсенең Татарстан Республикасы Саба районы бүлеге<br>Саба муниципаль районы Финанс–бюджет палатасы<br>Татарстан Республикасы финанс Министрлыгының казначылык департаментының Саба территориаль бүлеге | 06.05.2016 |
| 16 | Гигиена һәм эпидемология үзәге сәламәтлек саклау Федераль бюджет учреждениясенең Татарстан Республикасы Саба районы буенча филиалы<br>Саба районы дәүләт ветеринария берләшмәсе | 13.05.2016 |
| 17 | “Рамазан” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Сабагро” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 16.09.2016 |
| 18 | РФ пенсия фонды идарәсенең ТР Саба һәм Теләче районнары буенча идарәсе<br>“Россгострах” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең ТР Филиалы Б.Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе Агентлыгы<br>Район кулланучылар җәмгыяте берлеге идарәсе<br>“ПМК-159” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 23.09.2016 |
| 19 | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты<br>Саба муниципаль район Советы<br>Саба муниципаль районы мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы<br>Саба муниципаль районы авыл хуҗалыгы идарәсе | 30.09.2016 |
| 20 | «Экопродукт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Саба тәрәзәләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте “Бердәм тәрәзә” хезмәте | 07.10.2016 |
| 21 | ТР ирекле янгынга каршы көрәш җәмгыятенең Саба районы филиалы<br>ТР буенча 129 нчы янгын сүндерү часте<br>ТР зона эзләү коткару хезмәтенең 4 нче отряды<br>Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең Саба отряды Шәмәрдән аерымланган посты | 14.10.2016 |
| 22 | “Универмаг” сәүдә үзәге, | 21.10.2016 |

| | | |
|---|---|---|
| | “ Герат” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте,<br>“Мир” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте,<br>“ФРГ” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте,<br>ЧП “ Хасанов”, ЧП “Мубаракзянов, ЧП “Иванов”,<br>ИП “Хасанов Б.Х.”,<br>“Линда” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | |
| 23 | Ш.Биктимеров исемендәге район мәдәният йорты, Хөснулла һәм Аллаһияр Вәлиуллиннар исемендәге балалар сәнгать мәктәбе, балалар иҗат үзәге,<br>Ә.Кәримуллин исемендәге район үзәк китапханәсе | 28.10.2016 |
| ШӘМӘРДӘН ЗОНАСЫ | | |
| 1 | Шәмәрдән лицее | 13.02.2016 |
| 2 | Шәмәрдән участок шифаханәсе | 18.02.2016 |
| 3 | Шәмәрдән магистраль газ үткәргечләр линия-җитештерү идарәсе | 25.02.2016 |
| 4 | “Торак-коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күптармаклы җитештерү предприятиясе” ачык акционерлык җәмгыяте | 03.03.2016 |
| 5 | “Шәмәрдән ашлык кабул итү предприятиесе” ачык акционерлык җәмгыяте | 10.03.2016 |
| 6 | “ТАТМИТАгро” җаваплылыгы чикләнгән | 17.03.2016 |
| 7 | “Шәмәрдән нефть продуктлары” ачык акционерлык җәмгыяте | 24.03.2016 |
| 8 | Югары Утар балалар интернат-йорты | 31.03.2016 |
| 9 | “Яшьлек” мәдәни спорт үзәге | 07.04.2016 |
| 10 | Шәмәрдән сәнгать мәктәбе | 14.04.2016 |
| 11 | Шәмәрдән тимер юл станциясе | 21.04.2016 |
| 12 | Шәмәрдән “Салават күпере” балалар бакчасы<br>Шәмәрдән “Әкият” балалар бакчасы | 28.04.2016 |
| 13 | “МОНО-СТРОЙ” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 05.05.2016 |
| 14 | “Бетапром” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“СМИТ” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 12.05.2016 |

4 кушымта
Саба муниципаль район башлыгының
22.12. 2015 ел №182-р карары
белән расланды

Учреждение, оешма һәм предриятиеләр арасында
“Талант-шоу - 2016”
дип исемләнгән конкурс-кичәне бәяләү өчен жюри составы

| | | |
|---|---|---|
| | Саба зонасы буенча: | |
| 1 | Гүзәлов А.Н. | - “Саба үзәкләштерелгән клублар системасы” директоры (килешү буенча) |
| 2 | Габделхаков А.Г. | - Ш.Биктимеров исемендәге район мәдәният йорты белгече (килешү буенча) |
| 3 | Габделхаков Г.Г. | - Ш.Биктимеров исемендәге район мәдәният йорты методисты (килешү буенча) |
| 4 | Заһидуллин Р.Ф. | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы |
| 5 | Мөбәрәкҗанова А.З. | - Аллаһияр һәм Хөснулла Вәлиуллиннар исемендәге балалар сәнгать мәктәбе хореографы (килешү буенча) |
| 6 | Нурисламова Э.И. | - Ш.Биктимеров исемендәге район мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе (килешү буенча) |
| 7 | Нурмөхәммәтова Г.В. | - Ш.Биктимеров исемендәге район мәдәният йорты белгече (килешү буенча) |
| 8 | Хафизова Ч.Ф. | - Аллаһияр һәм Хөснулла Вәлиуллиннар исемендәге балалар сәнгать мәктәбе директоры (килешү буенча) |
| | Шәмәрдән зонасы буенча: | |
| 1 | Әсретдинова Р.С. | - Шәмәрдән мәдәният йортының үзешчән сәнгать җитәкчесе (килешү буенча) |
| 2 | Хаҗиева Р.И. | - Шәмәрдән мәдәният йорты директоры (килешү буенча) |
| 3 | Харрасова Л.А. | - Шәмәрдән балалар сәнгать мәктәбе укытучысы (килешү буенча) |
| 4 | Хуҗина А.Н. | - Шәмәрдән балалар сәнгать мәктәбе хореографы (килешү буенча) |